**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы**

Карар

№ 31 20 гыйнвар 2017 ел

**«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә Юстиция органына дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Уставына кертелгщн үзгәрешләр һәм өстәмәләр дәүләт теркәвеннән соң махсус мәгълүмати стендларда игълан ителергә тиеш.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үз көченә керә.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Г.Дәүләтшин

Кушымта № 1
Аксубай муниципаль районы
Иске Кыязлы авыл җирлеге
Советы карарына
20.01.2017 ел №31

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1.7 статьяны 15 пункт белән тулыландырырга:

«15) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.

2. 47 статьяның 2 өлеше түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырылырга:

Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чаралар үткәрә.